**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
“23” сентябрь 2020 ел

КАРАР
№ 9.

Татарстан Республикасы Әтнә район Советының 16.04.2018 елдагы № 102 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында” Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары җитәкчеләренә, белгечләренә һәм хезмәткәрләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 05.08.2020 ел, № 655 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар чыгарды:

1. Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмаларның җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында” Татарстан Республикасы Әтнә район Советының 16.04.2018 ел, № 102 карары белән билгеләнгән тәртиптә, 2020 елның 1 октябреннән арттырырга,

2. Татарстан Республикасы Әтнә район Советының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында” 16.04.2018 елның № 102 карары белән

расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

- 1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладының күләме 11 493,0 сум тәшкил итә.".

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы Рәисенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы -
Әтнә район Советы рәисе Г.Г.Хәкимов